**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО**
**КОМИТЕТА**
**ТЕТЮШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39
тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

От 27.08.2020 № 408

**2020 елның III кварталына Тәтеш муниципаль районы буенча, яшь гаиләләргә торак сатып алуга яисә аерым торак йорт төзелешенә бирелә торган социаль түләүләрнең күләмен исәпләү өчен, торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача норматив бәясен раслау турында**

“Россия Федерациясе гражданнарын һәркем өчен дә булган һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында”гы 2017 елның 30 декабрендәге 1710 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын, “ 2020 елның икенче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча, торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача норматив бәясе һәм 2020 елның III кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясенең күрсәткечләре турында”гы 2020 елның 29 июнендәге 351/пр номерлы Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгын, “Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәтләре белән тәэмин итү” дәүләт программасын раслау турында”гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы карарын гамәлгә ашыру максатынан, Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2020 елның III кварталына Тәтеш муниципаль районы буенча, яшь гаиләләргә торак сатып алуга яисә аерым торак йорт төзелешенә бирелә торган социаль түләүләрнең күләмен исәпләү өчен, торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача норматив бәясен 53024 сум күләмендә билгеләргә.
2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары А.Ф.Әхмәтшин өстенә йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Б.Семенычев**